Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

31 октябрь 2022 ел № 172

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган өлкәдәге бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы «Бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында»гы карары нигезендә

Әлмәт муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган өлкәдәге бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 30 октябрендәге 9 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 137 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 167 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районындагы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи хезмәт хакы

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи окладларның күләме, сумнарда |
|---|---|
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 16 263 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 15 785 |
| Бүлек җитәкчесе | 15 187 |
| Бүлек җитәкчесе урынбасары | 14 470 |
| Баш белгеч | 13 752 |

| | |
|---|---|
| Әйдәп баручы белгеч | 13 035 |
| I категория белгеч | 12 198 |
| II категория белгеч | 12 078 |
| Белгеч | 11 958» |

1.2. 2 нче кушымта таблицасында «11 498» санын «11 958» санына алыштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.

3. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә элек чыгарылган хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов